**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№ 4705**
**16.09.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт
хезмәтләре исемлегенә
үзгәрешләр кертү турында

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 июнендәге 151-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре исемлегенә (Башкарма комитетның 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 нче, 2018 елның 2 августындагы 4343 нче, 2019 елның 5 мартындагы 1144 нче, 2019 елның 23 маендагы 2663 нче карарлары редакциясендә), 24 пунктны алып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет каршындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин